«РАСЛЫЙМ»
Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр
__________ Р.Т. Борhанов
«__» __________ 2020 нче ел

Төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә төп гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе

# ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты

“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ”
Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе
тарафыннан әзерләнде

**ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕННӘН төп дәүләт имтиханы**

**Төп дәүләт имтиханы (ТДИ) рәвешендә төп гомуми белем бирү мәгариф программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясе**

**ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә варианты**

**“ПЕДАГОГИК ҮЛЧӘНЕШЛӘР ФЕДЕРАЛЬ ИНСТИТУТЫ” Федераль дәүләт бюджет фәнни учреждениесе тарафыннан әзерләнде**

**ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ буенча 2020 елгы төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү материалларының күрсәтмә вариантына аңлатмалар**

2020 елгы күрсәтмә вариант белән танышканда шуны истә тотарга кирәк: күрсәтмә вариантка кертелгән биремнәр 2020 елда КҮМ вариантлары ярдәмендә тикшереләчәк эчтәлекнең барлык элементларын чагылдырмый. 2020 елгы имтиханда контрольдә тотылырга мөмкин эчтәлек элементларының тулы исемлеге эчтәлек элементлары кодификаторында һәм www.fipi.ru сайтында урнаштырылган төп дәүләт имтиханын уздыру өчен укучыларны әзерләү дәрәҗәсенә карата таләпләр кодификаторында китерелгән.

Күрсәтмә вариант имтиханда катнашучы теләсә кайсы кешегә һәм киң җәмәгатьчелеккә имтихан эшенең структурасы, биремнәрнең саны һәм формасы, шулай ук аларның катлаулылык дәрәҗәсе турында күзаллау төзергә мөмкинлек бирү өчен каралган. Киңәйтелгән җаваплы биремнәрнең үтәлешен бәяли торган әлеге вариантка кертелгән критерийлар киңәйтелгән җавап язмасының тулылыгына һәм дөреслегенә карата таләпләр турында күзаллау тудырырга мөмкинлек бирәчәк.

Әлеге белешмәләр имтиханда катнашучыларга 2020 елда җәмгыять белеме буенча имтихан тапшыруга әзерлек стратегиясен эшләү мөмкинлеген бирә.

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

**Җәмгыять Белеме буенча 2020 елга**
**төп дәүләт имтиханында контроль үлчәү матриалларының**
**күрсәтмә варианты**

**Эшне башкару буенча күрсәтмә**

Имтихан эше 24 биремне үз эченә алган ике өлештән тора: кыска җаваплы 17 бирем һәм киңәйтелгән җаваплы 7 бирем.

Җәмгыять белеме буенча имтихан эшен башкаруга 3 сәгать (180 минут) вакыт бирелә.

2–5, 7–11, 13, 14, 16–18 нче биремнәргә җаваплар дөрес җавап номерына туры килгән бер цифр белән языла. 15, 19 нчы биремнәргә җавап булып саннар эзлеклелеге тора. 20 нче биремгә җавап булып сүз (сүзтезмә) тора. Җавапларны эш текстында бирелгән җавап урынында өтерләрсез һәм бернинди дә буш ара калдырмыйча язып куегыз, аннан соң 1 нче номерлы җаваплар бланкына күчереп языгыз.

1, 6, 12, 21-24 нче биремнәр 2 нче номерлы бланкта үтәлә. 21-24 нче биремнәрне үтәү өчен тексттан кирәкле мәгълүматны сайлап алырга, аның аерым бер нигезләмәләрен ачарга (шул исәптән мисаллар өстендә); тексттан алынган мәгълүматларны курсны өйрәнү барышында алынган белем белән туры китерергә; булган белемнәрне социаль ситуацияләрне анализлаганда кулланырга; үз фикереңне белдерергә һәм исбатларга кирәк.

Барлык бланклар куе кара паста белән тутырыла. Гельле яки капиллярлы ручка куллану рөхсәт ителә.

Эшне башкарганда, караламадан файдаланырга ярый. **Эшегезне бәяләгәндә, караламадагы, шулай ук контроль бәяләү материаллары текстындагы язмаларыгыз исәпкә алынмаячак.**

Биремнәрне үтәгәндә алган балларыгыз бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремнәргә дөрес җавап бирергә һәм күбрәк балл җыярга тырышыгыз.

Эш тәмамланганнан соң, 1 нче һәм 2 нче бланкларда һәр биремгә җавапның дөрес номеры язылуын тикшерегез.

***Уңышлар телибез!***

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки



***1, 6 һәм 12 нче биремнәргә җавап өчен 2 нче номерлы ЖАВАП БЛАНКЫН файдаланыгыз. Башта биремнең номерын, аннан соң аңа җавап язып куегыз. Җавапларны ачык һәм аңлаешлы итеп языгыз.***

***2-5, 7-11, 13-20 нче биремнәргә җавап булып цифрлар, цифрлар эзлеклелеге яки сүз (сүзтезмә) тора. Җавапларны башта эшнең текстында күрсәтегез, аннан соң аларны 1 нче номерлы ҖАВАПЛАР БЛАНКЫНДА бирем номерының уң ягына беренче шакмактан башлап язарга кирәк. Җавабыгызны буш ара калдырмыйча, өтер һәм башка өстәмә символлар куймыйча языгыз. Һәр цифрны яисә хәрефне бланктагы үрнәктә күрсәтелгән тәртиптә аерым шакмакка языгыз.***

**1** Санап үтелгән төшенчәләрнең кайсылары, беренче чиратта, җәмгыятьнең сәяси өлкәсен тасвирлаганда кулланыла?

*Страта; табыш; хакимият; демократия; милек.*

Тиешле төшенчәләрне языгыз һәм теләсә кайсының мәгънәсен ачыклагыз. Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**2** Дәрестә укучылар бер гаилә парының аерылышу мисалында РФ гаилә кануннарын өйрәнделәр. Әлеге уку эшчәнлегенең субъектын билгеләгез.

1) гаилә законнары
2) дәрес
3) укучылар
4) гаилә пары

Җавап: ☐

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

**3**

Җәмгыять турындагы әлеге фикерләр дөресме?
А. Җәмгыять табигатьнең бер өлеше булып тора.
Б. Җәмгыять структурасына иҗтимагый тормыш өлкәләре керә.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**4**

Унынчы сыйныфтагы гимназия укучысы Виолетта дәрәҗәле саналган артист осталыгы бәйгесендә җиңү яулады. Ул шулай ук балалар вокал студиясендә шөгыльләнә. Виолетта белем алуның кайсы дәрәҗәсендә?
1) башлангыч гомуми
2) төп гомуми
3) урта гомуми
4) урта һөнәри

Җавап: ☐

**5**

Хәзерге дөньяда фәннең роле турындагы әлеге фикерләр дөресме?
А. Фән кешегә әйләнә-тирә дөнья турындагы белемнәрне системалаштырырга ярдәм итә.
Б. Фән алынган нәтиҗәләрнең дөреслегенә омтыла.
1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐





**6**

Балигъ булган Роман Р.-га билгесез абоненттан SMS-хәбәр килгән: «Хөрмәтле клиент! Сезнең картагыз ябылды, рөхсәтсез акча алу омтылышы булган.
Счеттан файдалануны яңарту өчен, * * * телефон номерына үзегезнең картагыз буенча мәгълүматларны (№ һәм PIN-код) хәбәр итегез. Якын арада мәсьәлә хәл ителәчәк. Банк Д.».
Роман Р.-ның шәхси финанслары өчен бу вәзгыятьнең куркынычлыгы нидән гыйбарәт? Бу хәлдә аңа дөресендә нишләргә?
Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**7**

Санап үтелгәннәрнең кайсысы җитештерү факторларына (ресурсларына) карый?
1) хезмәт 2) керем 3) салым 4) эш хакы

Җавап: ☐

**8**

Z илендә товар җитештерү һәм акча әйләнеше бар. Нинди өстәмә мәгълүмат Z иленең икътисады базар характерында булуы турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә?
1) Дәүләт хезмәткәрләргә хезмәт хакы күләмен билгели.
2) Финанс министрлыгы алынган табышны ничек куллану мәсьәләсен хәл итә.
3) Балигъ булмаган хезмәткәрләргә ташламалы хезмәт шартлары бирелгән.
4) Җитештерүче мөстәкыйль рәвештә нәрсәне һәм күпме җитештерергә кирәклекне билгели.

Җавап: ☐

**9** Ресурсларның чикләнгән булуы турындагы әлеге фикерләр дөресме?

А. Ресурсларның чикләнгән булуы проблемасы заманча фән белән тулысынча хәл ителергә мөмкин.

Б. Ресурсларның чикләнгән булуы җәмгыять ихтыяҗларының артуы белән бәйле.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**10** Яшүсмерләр дә, өлкәннәр дә нинди социаль роль уйный ала?

1) кулланучы
2) сайлаучы
3) урта мәктәп укучысы
4) машина йөртүче

Җавап: ☐

**11** Социаль низаг турындагы әлеге фикерләр дөресме?

А. Социаль низаг һәрвакыт тискәре нәтиҗәләргә китерә.

Б. Социаль конфликтлар рәвеше һәм үсеш характеры буенча аерылалар.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел


Җавап: ☐





**12** Z иленең балигъ булган кешеләре белән үткәрелгән социологик сораштырулар барышында кешегә (белгечлек буенча юристка түгел) хокукның кайсы тармакларын күбрәк белү кирәклеген билгеләргә тәкъдим иттеләр (берничә җавап бирергә мөмкин иде).

Сораштыру нәтиҗәләре (җавап бирүчеләр санының %ында) гистограммада күрсәтелгән.




а) Охшашлык һәм б) сораштыруда катнашучыларның позицияләрендәге аермалык турында берәр нәтиҗә формалаштырыгыз. а) Охшашлык; б) аермалык нәрсә белән аңлатылганлыгы турындагы фаразларыгызны әйтегез.

Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

**13**

Z илендә хакимият гражданнарның хокукларын чикләгән һәм аларның шәхси тормышын тулысынча контрольдә тотарга омтылган бер сәяси партиягә карый. Парламентка даими сайлаулар булуга карамастан, ул әлеге партия әгъзаларыннан гына формалаша. Илдә бер сәяси идеология өстенлек итә. Китерелгән мәгълүматлар нигезендә Z дәүләте турында нинди нәтиҗә ясарга мөмкин?

1) демократик
2) монархия
3) федератив
4) тоталитар

Җавап: ☐

**14**

Референдум турындагы әлеге фикерләр дөресме?

А. Референдум бөтен җәмгыять һәм һәрбер граждан өчен мөһим булган мәсьәлә буенча бөтен халык тавыш бирүен күздә тота.

Б. Референдумда кабул ителгән карарлар иң югары юридик көчкә ия һәм дәүләт хакимияте органнары тарафыннан раслануга мохтаҗ түгел.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**15**

Кешенең һәм гражданның хокук һәм ирекләре белән хокук төркемнәре арасындагы тәңгәллекне билгеләгез: беренче багананың һәр элементына икенче баганадан тиешле элементны сайлап алыгыз.

| КЕШЕНЕҢ ҺӘМ ГРАЖДАННЫҢ ХОКУК ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕ | ХОКУК ТӨРКЕМНӘРЕ |
|---|---|
| А) яшәүгә хокук | 1) граждан (шәхси) |
| Б) дәүләт эшләре белән идарә итүдә катнашу хокукы | 2) сәяси |
| В) эшкуарлык эшчәнлеге ирекге | 3) социаль-икътисади |
| Г) вөҗдан ирекге һәм дин тоту ирекге | |
| Д) сайлау һәм сайлану хокукы | |

Сайланган саннарны таблицага тиешле хәрефләр астында языгыз. Җавап:

| А | Б | В | Г | Д |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |





**16**

Хокукый нормалар, башка социаль нормалардан аермалы буларак,

1) дәүләт көче белән хуплана
2) кешенең үз-үзен тотышын җайга сала
3) җәмгать фикере көченә таяна
4) үз-үзен тоту үрнәкләрен үз эченә ала

Җавап: ☐

**17**

Граждан К. улының туган көненә үзенең атомобилен бүләк итә. Бу мисал, граждан К.-ның, барыннан да элек, аның мөлкәтенә мөнәсәбәтендә милекче буларак кайсы хокукын күрсәтеп тора?

1) ия булу
2) мирас итеп бирү
3) файдалану
4) идарә итү

Җавап: ☐

**18**

РФ дә коррупциягә каршы тору турындагы әлеге фикерләр дөресме?
Россия Федерациясендә коррупциягә каршы тору түбәндәге принцип нигезендә гамәлгә ашырыла:

А. кеше һәм гражданның төп хокукларын һәм кеше ирекген тану, тәэмин итү һәм яклау.

Б. дәүләтнең граждан җәмгыяте институтлары, халыкара оешмалар һәм физик затлар белән хезмәттәшлек итүе.

1) А гына дөрес
2) Б гына дөрес
3) ике фикер дә дөрес
4) ике фикер дә дөрес түгел

Җавап: ☐

**19** Укытучы, кешенең асылын ачып, кешенең һәм башка җан ияләренең охшаш сыйфатларын, шулай ук кешене башка тереклек ияләреннән аерып торган сыйфатларны характерлады.

Таблицаның беренче баганасына охшаш якларның, ә икенче баганага аермалы якларның тәртип номерларын сайлагыз һәм язып куегыз.

1) әйләнә-тирә мохит шартларына җайлашу
2) эшчәнлек максатларын һәм бурычларын кую сәләте
3) инстинкт һәм рефлекслар
4) аң һәм сөйләм

| Охшаш яклар | | Аермалы яклар | |
|---|---|---|---|
| | | | |

**20** Таблицадагы бушлыкларны тутырыгыз.

| **Дәүләт хакимияте органы** | **Вәкаләтләр** |
|---|---|
| ... | Дәүләт бюджетын эшләү һәм үтәү |
| РФ Федераль Собраниесе | РФ законнарын эшләү һәм кабул итү |

Җавап:______________________________

***Текстны укыгыз һәм 21-24 биремнәрне үтәгез. Биремнәргә җавапларны язу өчен 2 нче номерлы җаваплар бланкыннан файдаланыгыз. Башта биремнең номерын, аннары аңа киңәйтелгән җавап языгыз. Җавапларны ачык һәм аңлаешлы итеп языгыз.***

Без белем, һөнәри күнекмәләр кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Һаман саен катлаулана барган белемнәрсез эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлый алачак. Ә моның өчен кешенең гомуми интеллигентлылыгы, аның яңа әйберләр булдыру сәләте, һәм, әлбәттә, машина үз өстенә ала алмаган әхлакый җаваплылык кирәк булачак. ... кешегә гади генә кеше түгел, ә фән кешесе, машина һәм роботлар гасырында барган бар нәрсә өчен җавап бирә торган кеше булу кебек авыр һәм катлаулы бурыч йөкләнгән. Гомуми белем иҗади кешене, иҗат итүче, барлык төр яңаны тудыручы һәм һәрбер яңалыкның әхлак ягы өчен җавап бирә торган киләчәк кешесен тудырырга мөмкин.

Уку – кечкенәдән үк менә нәрсә кирәк хәзер яшь кешегә. Һәрвакыт укырга кирәк. Барлык зур галимнәр дә гомерләренең ахырына кадәр өйрәтеп

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки



кенә калмаганнар, ә үзләре дә укыганнар. Укудан туктасаң, укыта да алмыйсың. Чөнки белем һаман үсә һәм катлаулана бара. Шуны истә тотарга кирәк: уку өчен иң уңайлы вакыт – яшьлек. Нәкъ менә яшь чакта, балачакта, яшьлегендә кешенең акылы яңалыкны кабул итүгә иң сәләтле.

Юк-барга, "ялга" вакытыгызны әрәм итмәгез, кайчакта алар иң авыр эшкә караганда да ялыктыра төшә, акылыгызны ахмак һәм максатсыз "мәгълүмат"ның болганчык ташкыннары белән тутырмагыз. Үзегезне өйрәнүләр өчен, яшь чакта гына җиңел һәм тиз үзләштерелә торган белем һәм күнекмәләр алу өчен саклагыз.

Һәм шушында мин яшь егетнең авыр көрсенүен ишетәм: безнең яшьләргә нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез сез! Тик укырга гына. Ә ял, күңел ачу кайда соң? Безгә нәрсә, шатланмаскамы инде хәзер?

Юк, юк. Белем һәм күнекмәләр алу – шул ук спорт. Укудан шатлык таба белмәгәндә өйрәнү авыр. Укуны, белем алуны яратырга кирәк һәм ял итү, күңел ачу формаларының да нәрсәгәдер өйрәтергә, тормышта кирәк булган ниндидер сәләтләрне үстерергә ярдәм итә торганнарын гына сайларга кирәк...

Укуны яратырга өйрәнегез!

*(Д. С. Лихачёв)*

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

**21** Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып алыгыз һәм аларның һәркайсына исем куешыгыз.

**22** Автор XXI гасырда кешенең җитештерүдәге ролен ничек тасвирлый? Аның фикеренчә, кешегә нинди сыйфатлар кирәк булачак? (Теләсә нинди ике сыйфатны күрсәтегез.) Автор фикеренчә, ни өчен яшь кешегә кече яшьтән үк укырга кирәк? (Тексттан файдаланып, ике сәбәпне күрсәтегез.)

**23** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу формалары тәкъдим итә? Мондый формаларга ике мисал китерегез; һәр очракта әлеге форманың нинди сыйфатларны үстерүен күрсәтегез.

**24** Автор "һәрвакыт укырга кирәк" дип саный. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән файдаланып, кешегә бөтен гомере буена өзлексез белем алу кирәклеген ике дәлил (аңлатма) белән раслагыз.

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки



## Җәмгыять белеме буенча имтихан эшенең үтәлешен бәяләү системасы

15 нче биремнән тыш, кыска җавап таләп ителәгә торган дөрес җаваплы һәрбер биремгә 1 балл куела. 15 нче биремгә җавап түбәндәге принцип буенча бәяләнә: 2 балл – хаталар юк; 1 балл – бер хата җибәрелгән; 0 балл – ике һәм аннан да күбрәк хата җибәрелгән.

| Бирем номеры | Дөрес җавап | Бирем номеры | Дөрес җавап |
|---|---|---|---|
| 2 | 3 | 13 | 4 |
| 3 | 2 | 14 | 3 |
| 4 | 3 | 15 | 12312 |
| 5 | 3 | 16 | 1 |
| 7 | 1 | 17 | 4 |
| 8 | 4 | 18 | 3 |
| 9 | 2 | 19 | 1324 |
| 10 | 1 | 20 | РФ Хөкүмәте |
| 11 | 2 | | |

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

***Эшне башкару күрсәтмәсе нигезендә, барлык җавапларны 1 нче һәм 2 нче җаваплар бланкына күчерергә онытмагыз. Һәр җавапның тиешле бирем номеры янында язылуын тикшерегез.***

**Киңәйтелгән җавапны таләп итә торган биремнәрнең үтәлешен бәяләү критерийлары**

1 Санап үтелгән төшенчәләрнең кайсылары,беренче чиратта, җәмгыятьнең сәяси өлкәсен тасвирлаганда кулланыла?

*Страта; табыш; хакимият; демократия; милек.*

Тиешле төшенчәләрне языгыз һәм теләсә кайсы берсенең мәгънәсен ачыклагыз. Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) төшенчәләр: хакимият, демократия;<br>2) төшенчәнең мәгънәсе, мәсәлән: хакимият – үз ихтыярыңны тагу, башкалар белән идарә итү яки башка кешеләргә йогынты ясау мөмкинлеге /демократия<br>– чыганагы халык үзе булган сәяси режим.<br>Төшенчәнең мәгънәсенә якын булган башка билгеләмә яки төшенчәнең мәгънәсен аңлату китерелергә мөмкин. | |
| Ике дөрес төшенчә дөрес язылган, теләсә кайсы берсенең мәгънәсе ачылган. | 2 |
| Дөрес төшенчәләр белән беррәттән, бер яки берничә "артык" төшенчә язылган, дөрес төшенчәнең мәгънәсе ачылган.<br>ЯКИ Ике дөрес төшенчә генә дөрес язылган.<br>ЯКИ Бер генә дөрес төшенчә дөрес язылган, мәгънәсе ачылган. | 1 |
| Дөрес төшенчәләр белән беррәттән, бер яки берничә "артык" төшенчә язылган, "артык" төшенчәнең генә мәгънәсе ачылган.<br>ЯКИ Дөрес төшенчәләр белән беррәттән бер яки берничә "артык" төшенчә язылган, дөрес төшенчәнең мәгънәсе ачылмаган яки дөрес аңлатылмаган.<br>ЯКИ Бары бер генә дөрес төшенчә язылган.<br>ЯКИ Биремнең таләбенә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел. | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки




6 Балигъ булган Роман Р.га билгесез абоненттан SMS-хәбәр килгән: «Хөрмәтле клиент! Сезнең картагыз ябылды, рөхсәтсез акча алу омтылышы булган. Счеттан файдалануны яңарту өчен, * * * телефон номерына үзегезнең картагыз буенча мәгълүматларны (№ һәм PIN-код) хәбәр итегез. Якын арада мәсьәлә хәл ителәчәк. Банк Д.».
Роман Р. ның шәхси финанслары өчен бу вәзгыятьнең куркынычлыгы нидән гыйбарәт? Бу хәлдә аңа дөресендә нишләргә?

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга мөмкин:<br>1) беренче сорауга җавап, мәсәлән: мөгаен, болар конфиденциаль мәгълүматны һәм барлык акчаларны үзләштерергә планлаштырган алдакчыдыр;<br>2) икенче сорауга җавап, мәсәлән: беркайчан да үз банк счетының /карта номерын һәм PIN-кодны хәбәр итмәскә; клиентлар өчен "кайнар линия"гә һәм / яки банк куркынычсызлыгы хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә. Сорауларга җаваплар мәгънәсе буенча якын булган башка формулировкалар белән дә китерерлергә мөмкин. | |
| Ике сорауга дөрес җавап бирелгән | 2 |
| Теләсә кайсы бер сорауга дөрес җавап бирелгән | 1 |
| Биремнең таләбенә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

**12**

Z иленең балигъ булган кешеләре белән үткәрелгән социологик сораштырулар барышында кешегә (белгечлек буенча юристка түгел) хокукның кайсы тармакларын күбрәк белү кирәклеген билгеләргә тәкъдим иттеләр (берничә җавап бирергә мөмкин иде).
Сораштыру нәтиҗәләре (җавап бирүчеләр санының %ында) гистограммада күрсәтелгән.




а) Охшашлык һәм б) сораштыруда катнашучыларның позицияләрендәге аермалык турында берәр нәтиҗә формалаштырыгыз. А) Охшашлык; б) аермалык нәрсә белән аңлатылганлыгы турындагы фаразларыгызны әйтегез.
Җавапны, биремнең номерын күрсәтеп, 2 нче номерлы җаваплар бланкына языгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | |
|---|---|
| Дөрес җавапта нәтиҗәләр формалаштырылырга һәм фаразлар әйтелергә тиеш:<br>а) охшашлык турында, мәсәлән: яшьләре буенча ике төркемгә дә караган гражданнар тигез дәрәҗәдә, кешегә конституциячел хокукны белергә кирәк, дип саныйлар (чөнки һәр граждан үз хокукларын һәм бурычларын, конституциячел төзелешнең нигезләрен белергә тиеш);<br>б) аермалык турында, мәсәлән: 31-45 яшьлек граждан белән чагыштырганда, 46-60 яшьлек гражданнар, кешегә граждан хокукын белү кирәк дип саныйлар (чөнки граждан хокуклары мөлкәти мөнәсәбәтләрне, милек мәсьәләләрен, шартнамәләрне төзүне һ.б. җайга сала; кагыйдә буларак, 46-60 яшенә инде күпләр төрле милеккә ия, шунлыктан биләү, файдалану һәм идарә итү аларны кечерәк яшьтәге гражданнарга караганда күбрәк борчый).<br>Охшашлык һәм аермалык турында башка нәтиҗәләрне дә формалаштыр | |





| | |
|---|---|
| Охшашлык һәм аерымлык турында берәр нәтиҗә формалаштырылган, аларның һәркайсы буенча урынлы фараз тәкъдим ителгән. | 4 |
| Бер-ике нәтиҗә формалаштырыла, бары берсе буенча гына урынлы фараз тәкъдим ителгән. | 3 |
| Бары ике генә нәтиҗә формалаштырылган | 2 |
| Бары бер генә нәтиҗә формалаштырылган | 1 |
| ЯКИ Биремнең таләбенә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| | *4* |

Без белем, һөнәри күнекмәләр кеше язмышында хәлиткеч роль уйнаячак гасырга керәбез. Һаман саен катлаулана барган, белемнәрсез эшләргә, файда китерергә мөмкин булмаячак... Кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлый алачак. Ә моның өчен кешенең гомуми интеллигентлылыгы, аның яңа әйберләр булдыру сәләте, һәм, әлбәттә, машина үз өстенә ала алмаган әхлакый җаваплылык кирәк булачак. ... кешегә гади генә кеше түгел, ә фән кешесе, машина һәм роботлар гасырында барган бар нәрсә өчен җавап бирә торган кеше булу кебек авыр һәм катлаулы бурыч йөкләнгән. Гомуми белем иҗади кешене, иҗат итүче, барлык яңаны тудыручы һәм һәрбер яңалыкның әхлак ягы өчен җавап бирә торган килечәк кешесен тудырырга мөмкин.

Уку – кечкенәдән үк менә нәрсә кирәк хәзер яшь кешегә. Һәрвакыт укырга кирәк. Барлык зур галимнәр дә гомерләренең ахырына кадәр өйрәтеп кенә калмаганнар, ә үзләре дә укыганнар. Укудан туктасаң, укыта да алмыйсың. Чөнки белем һаман үсә һәм катлаулана бара. Шуны да истә тотарга кирәк: уку өчен иң уңайлы вакыт - яшьлек. Нәкъ менә яшь чакта, балачакта, яшьлегендә кешенең акылы яңалыкны кабул итүгә иң сәләтле.

Юк-барга, "ялга" вакытыгызны әрәм итмәгез, кайчакта алар иң авыр эшкә караганда да ялыктыра төшә, акылыгызны ахмак һәм максатсыз "мәгълүмат"ның болганчык ташкыннары белән тутырмагыз. Үзегезне өйрәнүләр өчен, яшь чакта гына җиңел һәм тиз үзләштерелә торган белем һәм күнекмәләр алу өчен саклагыз.

Һәм менә шушында мин яшь егетнең авыр көрсенүен ишетәм: безнең яшьләргә нинди күңелсез тормыш тәкъдим итәсез сез! Тик укырга гына. Ә ял, күңел ачу кайда соң? Безгә нәрсә, шатланмаскамы инде хәзер?

Юк, юк. Белем һәм күнекмәләр алу - шул ук спорт. Укудан шатлык таба белмәгәндә, өйрәнү авыр. Уку, белем алуны яратырга кирәк һәм ял итү һәм күңел ачу формаларының да нәрсәгәдер өйрәтергә, тормышта кирәк булган нинди дер сәләтләрне үстерергә сәләтле акы булганнарын сайларга кирәк...

Укуны яратырга өйрәнегез!

*(Д.С. Лихачёв)*

**21** Текстның планын төзегез. Моның өчен текстның төп мәгънәви фрагментларын аерып алыгыз һәм аларның һәркайсына исем кушыгыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта план пунктлары текстның төп мәгънәви фрагментларына туры килергә һәм аларның һәрберсенең төп идеясен чагылдырырга тиеш.<br>Түбәндәге мәгънәви фрагментлар аерып алынырга мөмкин:<br>1) XXI гасырда мәгарифнең роле;<br>2) фән кешесенең әхлакый җаваплылыгы;<br>3) яшьлек чоры – уку вакыты;<br>4) укудан тәм, шатлык таба белү.<br>План пунктларының башка (фрагментның төп идеясен бозмый торган) формулировкаларын һәм өстәмә мәгънәви блокларны бүлеп күрсәтү мөмкин. | |
| Текстның төп мәгънәви фрагментлары аерып бирелә, аларның исемнәре (план пунктлары) текстның һәр фрагментының төп идеясен чагылдыра.<br>Бүлеп күсәтелгән фрагментлар саны төрлечә булырга мөмкин. | 2 |
| Текстның мәгънә фрагментларының яртысыннан артыгы дөрес бүленгән, аларның исемнәре (план пунктлары) текстның тиешле өлешләренең төп идеяләрен чагылдыра.<br>Яисә текстның төп мәгънәви фрагментлары аерылган, ләкин барлык исемнәр (план пунктлары) текстның һәр фрагментының төп идеясен чагылдырмый. | 1 |
| Текстның төп фрагментлары аерылмаган.<br>ЯКИ Аерып бирелгән фрагментларның исемнәре (план пунктлары) текстның тиешле өлешләренең төп идеясенә туры килми, алар тиешле фрагментлардан өземтәләр булып торалар.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел. | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки



**22** Автор XXI гасырда кешенең җитештерүдәге ролен ничек тасвирлый? Аның фикеренчә, кешегә нинди сыйфатлар кирәк булачак? (Теләсә нинди ике сыйфатны күрсәтегез.) Автор фикеренчә, ни өчен яшь кешегә кече яшьтән үк укырга кирәк? (Тексттан файдаланып, ике сәбәпне күрсәтегез.)

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге **элементлар** булырга тиеш:<br>1) **беренче сорауга җавап**, мәсәлән: кеше яңа идеяләр кертәчәк, машина уйлый алмаган нәрсәләр турында уйлаячак;<br>2) **икенче сорауга җавап**, мәсәлән:<br>- кешенең гомуми интеллигентлылыгы;<br>- яңаны булдыру сәләте;<br>- әхлакый җаваплылык.<br>*(Икенче сорауга җавап текстта телгә алынган ике һәм аннан да күбрәк сыйфат күрсәтелгән очракта гына санала.)*<br>3) **өченче сорауга җавап**, мәсәлән:<br>- белем һәрвакыт үсеп һәм катлауланып тора;<br>- нәкъ менә яшь вакытта кеше акылының яңалыкны кабул итү дәрәҗәсе югарырак булла.<br>*(Өченче орауга җавап ике сәбәпне курсәткәндә генә санала.)*<br>Җавап элементлары цитата формасында да, текстның тиешле фрагментларының төп идеяләрен кыскача әйтү формасында да китерелергә мөмкин. | |
| Өч сорауга җаваплар дөрес бирелгән | 2 |
| Теләсә кайсы ике сорауга җаваплар дөрес бирелгән | 1 |
| Бары бер генә сорауга җавап дөрес бирелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

©2020Федеральнаяслужбапонадзорувсфереобразованияинауки

**23** Автор яшьләргә нинди ял һәм күңел ачу формалары тәкъдим итә? Мондый формаларга ике мисал китерегез; һәр очракта әлеге форманың нинди сыйфатларны үстерүен күрсәтегез.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Дөрес җавапта түбәндәге элементлар булырга тиеш:<br>1) сорауга җавап: автор нәрсәгәдер өйрәтергә, тормышта кирәк булган сәләтләрне үстерергә сәләтле булган «акыллы» ял һәм күңел ачу формаларын тәкъдим итә;<br>2) сыйфатын (билгесен) күрсәтеп, ике мисал, мәсәлән:<br>– спорт секциясендәге шөгыльләр көчне, житезлекне, ихтыяр көчен, партнер һәм көндәшләр белән хезмәттәшлек итү осталыгын үстерә;<br>– әдәби әсәрләрне уку образлы фикер йөртүне, бер-береңне аңлау, ярдәмләшү хисен үстерә, дөнья һәм кеше турындагы күзаллауларны киңәйтә.<br>Җавап элементлары мәгънәсе буенча якын булган башка формулировкаларда китерелергә мөмкин. | |
| Сорауга җавап бирелгән, ике мисал китерелгән, һәр очракта да сыйфат күрсәтелгән (барлыгы биш позиция) | 3 |
| Теләсә кайсы дүрт позиция дөрес китерелгән | 2 |
| Теләсә кайсы ике-өч позиция дөрес китерелгән | 1 |
| Теләсә кайсы бер позиция дөрес китерелгән<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *3* |





Автор "һәрвакыт укырга кирәк" дип саный. Тексттан һәм җәмгыять белеменнән файдаланып, кешенең бөтен гомере буена өзлексез белем алу кирәклеген ике дәлил (аңлатма) белән раслагыз.

| **Дөрес җавапның эчтәлеге һәм бәяләү буенча күрсәтмәләр** (җавапның мәгънәсен бозмый торган башка формулировкалар да рөхсәт ителә) | **Баллар** |
|---|---|
| Түбәндәге дәлилләр (аңлатмалар) китерелергә мөмкин:<br>1) хәзерге заманда белем бик тиз искерә, шуңа күрә аларны даими тулыландырырга, коррекцияләргә туры килә;<br>2) хәзерге заман кешеләре эшләрен еш үзгәртәләр, шуңа күрә яңа мәгълүматны, эшчәнлек төрләрен даими үзләштерергә туры килә.<br>Башка аргументлар (аңлатмалар) китерелергә мөмкин | |
| Ике дәлил (аңлатма) китерелгән | 2 |
| Бер дәлил (аңлатма) китерелгән | 1 |
| Биремнең таләбенә туры килми торган гомуми характердагы фикер йөртүләр китерелгән.<br>ЯКИ Җавап дөрес түгел | 0 |
| *Максималь балл* | *2* |

Төп гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестациясен үткәрү тәртибе нигезендә (Россия Мәгариф министрлыгы һәм Рособрнадзорның 07.11.2018 № 189/1513 боерыгы, Россия Юстиция министрлыгы тарафыннан 10.12.2018 № 52953 теркәлгән.)

«64. Имтихан эшләре ике эксперт тарафыннан тикшерелә. Экспертлар бер-берсеннән бәйсез рәвештә тикшерү нәтиҗәләре буенча имтихан эше биремнәренә һәр җавап өчен баллар куя. Ике эксперт куйган балларда сизелерлек аерма булган очракта, өченче тикшерү билгеләнә. Балларда сизелерлек аерма тиешле уку предметы буенча бәяләү критерийларында билгеләнгән.

Элек имтихан эшен тикшермәгән экспертлардан өченче эксперт предмет комиссиясе рәисе тарафыннан билгеләнә.

Өченче экспертка укучының имтихан эшен тикшергән экспертлар тарафыннан куелган баллар турында мәгълүмат бирелә. Өченче эксперт куйган баллар ахыргы булып тора».

Ике эксперт тарафыннан 1, 6, 12, 21-24 нче биремнәрнең теләсә кайсы өчен куелган баллар арасында 2 яки аннан да күбрәк аерма булса, баллар арасында шактый аерма бар дип санала. Өченче эксперт балларда сизелерлек аерма булган биремнәр җавапларын гына тикшерә.